СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

15.12.2025 г. Агрыз № 4-8

Әгерҗе муниципаль районы Советының 2022 елның 26 октябрендә кабул ителгән 20-8 номерлы «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының җирле үзидарә органнарында даими нигездә үз вәкаләтләрен башкаручы депутатлар, сайланма җирле үзидарә башлыклары, контроль-исәп органы рәисе, муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт хакын түләү нормативлары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 25 ноябрендә кабул ителгән 994 номерлы «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-исәп органнары рәисләре, урынбасарлары, аудиторлары, даими нигездә үз вәкаләтләрен башкаручы сайланган вазифаи затлар, җирле үзидарә органнары депутатлары, муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт хакын түләү нормативларын формалаштыру турында» 2018 елның 28 мартында кабул ителгән 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»гы карары нигезендә, Татарстан Республикасының Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1.Татарстан Республикасының Әгерҗе муниципаль районы Советының 2022 елның 26 июнендә кабул ителгән 20-8 номерлы «Татарстан Республикасының Әгерҗе муниципаль районының җирле үзидарә органнарының даими нигездә үз вәкаләтләрен башкаручы депутатлар, сайланма җирле үзидарә башлыклары, контроль-исәп органы рәисе, муниципаль хезмәткәрләр өчен хезмәт хакы түләү нормативлары турында»гы Карарына ( алга таба – Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә.

2. Хәзерге карарның 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керүен билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2025 елның 22 апрелендә кабул ителгән 46-6 нче номерлы «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының җирле үзидарә органнарының даими нигездә үз вәкаләтләрен башкаручы депутатлары, сайланма вазифаи затлары, контроль-исәп органы рәисе, муниципаль хезмәткәрләре өчен хезмәт хакы түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативларына

үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 26 октябрендә кабул ителгән 20-8 номерлы карарына 1нче номерлы кушымтасының 1 һәм 1.2 пунктларын көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Муниципаль район Башлыгы Л.Ф. Нургаянов

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы Советының
2025 елның 15.12 кабул ителгән
карарына 1нче кушымта

Татарстан Республикасының Әгерҗе муниципаль районы Советының 2022 елның 26 октябрендә кабул ителгән «Татарстан Республикасының Әгерҗе муниципаль районында даими нигездә үз вәкаләтләрен башкаручы депутатларның, сайланма җирле үзидарә башлыкларының, контроль-исәп органы рәисенең, җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт хакын түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында»гы 20-8 карарына

үзгәрешләр

1. Карарның 1.1. нче пунктын түбәндәге редакциядә язып чыгарырга:

«1.1. Әгерҗе муниципаль районы башлыгына, муниципаль район башлыгы урынбасарына, Әгерҗе муниципаль районының Контроль-исәп палатасы рәисе өчен айлык акчалата түләүне түбәндәге күләмдә билгеләргә:

| Эш урыны атамасы | Акчалата түләү күләме |
|---|---|
| Муниципаль район җитәкчесе | 44814 |
| Муниципаль район җитәкчесе урынбасары | 40334 |
| Контроль-исәп палатасы рәисе | 40334 |

1.2. Карарның 6 нчы пунктының 1 нче аскы пунктын түбәндәге редакциядә язып чыгарырга:
«1. Әгерҗе муниципаль районының җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазифасына карап, вазифаи хезмәт хакын түбәндәге күләмдә билгеләргә:

| Эш урынының исеме | Размер должностного оклада (в рублях) |
|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | 44013 |
| Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары | 39612 |
| Совет аппараты җитәкчесе | 39951 |
| Башкарма комитетның эшләр белән идарә итүчесе | 37073 |
| Башка җирле үзидарә органы җитәкчесе | 39443 |

| | |
|---|---|
| Башка җирле үзидарә органы җитәкчесе урынбасары | 36226 |
| - Совет, Башкарма комитет һәм башка җирле үзидарә органы бүлеге начальнигы | 30809 |
| Совет, Башкарма комитет һәм башка җирле үзидарә органы бүлеге начальнигы урынбасары | 26916 |
| Башкарма комитет һәм башка җирле үзидарә органы секторы мөдире | 24885 |
| Район башлыгы ярдәмчесе, район Башкарма комитеты җитәкчесе ярдәмчесе | 26916 |
| Совет, Башкарма комитет һәм башка җирле үзидарә органының баш белгече | 23869 |
| Совет, Башкарма комитет һәм җирле үзидарәнең башка органының әйдәп баручы белгече | 22176 |